КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 3 июнь г.Казань № 517

Татарстан Республикасында эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү яисә күрсәтелгән ширкәтләрне техник су белән тәэмин итү максатларында бакчачылык коммерциягә карамаган ширкәтләр һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләр тарафыннан җир асты суларын чыгару тәртибен раслау турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 19 статьясы, «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 14 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү яисә күрсәтелгән ширкәтләрне техник су белән тәэмин итү максатларында бакчачылык коммерциягә карамаган ширкәтләр һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләр тарафыннан җир асты суларын чыгару тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 3 июнь, 517 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү яисә күрсәтелгән ширкәтләрне техник су белән тәэмин итү максатларында бакчачылык коммерциягә карамаган ширкәтләр һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләр тарафыннан җир асты суларын чыгару тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 192 статьясы (алга таба - «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы), «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 14 пункты (алга таба - «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законы) нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасында эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү яисә күрсәтелгән ширкәтләрне техник су белән тәэмин итү максатларында бакчачылык коммерциягә карамаган ширкәтләр һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләр тарафыннан җир асты суларын чыгару механизмын (алга таба - эчәргә яраклы су белән тәэмин итү) регламентлый.

2. Бакчачылык коммерциягә карамаган ширкәтләр һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләр (алга таба - ширкәтләр) тарафыннан эчәр сулар белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында җир асты суларыннан файдалану дигәндә гражданнарның бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендә урнашкан бакча яисә яшелчәчелек җир кишәрлекләренең ширкәтләре һәм хокук ияләре тарафыннан алардан үз ихтыяҗлары өчен, шәхси, көнкүреш һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле булмаган башка ихтыяҗлар өчен бакчачылыкны яисә яшелчәчелекне алып бару һәм моның өчен уңай шартлар тудыру, шулай ук гражданнар тарафыннан бакчачылыкны алып бару яисә үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны алып бару территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен үзләштерүне тәэмин итү максатларында файдалануы аңлашыла.

3. Эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә ширкәтләрне техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган җир асты суларын чыгару «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә файдалануга тапшырылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә ширкәтләр тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм Россия Федерациясе Дәүләт гербы булган бланкның билгеләнгән формасын үз эченә алган лицензия рәвешендә, шулай ук лицензиянең аерылгысыз состав өлеше булган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

билгеләгән тәртиптә бирелгән җир асты байлыкларыннан файдалануның төп шартларын билгеләүче текст, график һәм башка кушымталарны үз эченә алган лицензия рәвешендә махсус дәүләт рөхсәте белән рәсмиләштерелә.

4. Эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә ширкәтләрне техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган җир асты суларын чыгару җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне үткәрмичә, файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасын уздырмыйча, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүмат, техник проектларны һәм башка проект документациясен килештерү һәм раслаусыз, шулай ук ширкәтләрнең квалификацияле белгечләргә, җир асты байлыкларыннан файдалануны нәтиҗәле һәм имин гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс һәм техник чараларга ия булуы яисә булачагы турында дәлилләр китермичә генә гамәлгә ашырыла.

5. Эчәр сулар белән тәэмин итү яисә ширкәтләрне техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты суларын чыгару җир асты су объектларын саклау кагыйдәләрен, шулай ук җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану һәм аларны саклау буенча төп таләпләрне үтәп башкарылырга тиеш.